СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

15 нче декабрь, 2023 ел Алабуга шәһәре № 305

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты структурасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортлар төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итү белән бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең норматив санын билгеләү турында» 2023 елның 1 ноябрендәге карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты структурасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Өлешле төзелеш өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге буенча белгеч санын - 1 данә берәмлектә билгеләргә (муниципаль хезмәткәр түгел).

2. Алабуга муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйкова) Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты структурасындагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә Алабуга муниципаль районы бюджетына тиешле үзгәрешләрне кертү турында карар проектын әзерләргә.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р.М. Нуриев